**“Балалар бакчасы милли тәрбия бирүдә төп баскыч”**

“Милли тәрбия алмаган кешенең киләчәге юк”-, дигән әйтем бар. Милли тәрбия бирү өчен милли мөхит булдыру шарт. Бүгенге көндә, ФДББС шартларында, милли аң формалаштыруның үзәге, сүнмәс учагы булып мәктәпкәчә тәрбия бирү оешмасы тора.

Мәктәпкәчә яшьтәге тәрбия учреждениеләре, берсүзсез, милли тәрбияне тормышка ашыруда беренче баскыч. Бары тик эшне дөрес оештырырга, тиешле юнәлеш кенә бирергә кирәк. Лениногорск шәһәренең № 4 нче “Карлыгач” балалар бакчасы милли тәрбия һәм белем бирү учреждениесе буларак, үзенә йөрүче сабыйларны һәр көнне ишекләрен киң ачып каршы ала. Без балаларга милли тәрбия бирүне гамәлгә ашырабыз, милли үзаңны үстерү өстендә эш алып барабыз. Бакчабызда барлык шөгелләр һәм күңел ачулар татар телендә үткәрелә. Балаларга күпьяклы белем һәм тәрбия бирү өчен барлык уңай шартлар тудырылган. Безнең бакчага йөрүче балалар капканы ачып керү белән милли мөхиткә эләгәләр.

Безнең максатыбыз: “Татарстан Республикасы” халыклары телләре турында”гы боерыкны тормышка ашыру, халкыбызның телен, мәдәниятен саклау һәм үстерү; балаларда милли үзаң, татар халкының мәдәниятенә, тарихына хөрмәт һәм сакчыл караш тәрбияләү өчен, уңайлы шартлар тудыру; балаларга гореф- гадәтләргә, тарихи үткәннәргә карата кызыксыну уяту, рухи мирасны өйрәнү, белү һәм саклау омтылышы тәрбияләү; милли мөхит, ата-аналар һәм гаилә белән берлектә уртак максатка юнәлтелгән бердәм тәрбия эшен алып бару.

“Үткәнен белмәгән халыкның киләчәге булмас”, – ди татар халык мәкале. Татар халкын милләт буларак саклап калу, үстерү, үткәннәр турында төкми-чәчми балаларыбызга тапшыру ─ хәзерге буынның төп вазифасы. Ана теле - сабыйларга аң-белем һәм тәрбия бирү өчен иң шифалы чишмә. Чишмәнең башы исә туган яктан башлана. Бездә тәрбия һәм белем алган балаларның милләтен хөрмәт итүче, инсафлы, әдәпле булып үсүләренә бернинди шигебез юк. Нәниләребездә әхлакый сыйфатлар тәрбияләүдә , ата- аналар да читтә калмый, алар белән без тыгыз элемтәдә торып эшлибез. Бакчабызда милли бәйрәмнәр, йолалар еш үткәрелә. “Сөмбелә”, “Каз өмәсе”, “Нәүрүз”, “Карга боткасы”, “Кич утыру”, “Сабантуй” – шундыйлардан. Аларда татар милли уеннары, җырлы- биюле уеннар, халык авыз иҗаты әсәрләре кулланыла.

## Балалар бакчасында милли тәрбия өйрәнү системасын проектлаштыруда эшне анализлау, милли тәрбиянең ролен ачыклау:

Милли рухи байлык аерым халыкның гына түгел, ул – гомум кешелек кыйммәтләренең нигезе. Димәк, балаларны кечкенәдән үк үз халкының, үз туган җиренең үзенчәлекләре белән таныштыру гомум кешелек кыйммәтләре белән таныштыруның башлангычы булып тора. Безнең бурыч – үткән буыннар туплаган рухи байлыкны саклап, баетып, аның кешелек тарафыннан иң кыйммәтле дип табылган үрнәкләрен балаларга җиткерү.
Мәктәпкәчә белем бирү оешмалары, Федераль дәүләт мәктәпкәчә белем бирү стандарты таләпләренә һәм үрнәк белем бирү программасына нигезләнеп, үзләренең белем бирү программасын төзи, раслый һәм тормышка ашыра. Бу очракта, һичшиксез, мәктәпкәчә белем бирү программасының инвариант (үзгәреш кертелми торган, гомуми күләмнең 60% ыннан ким булмаган) һәм вариатив (белем бирүдә катнашучылар төзегән – 40% тан артык булмаган) өлешләрдән торырга тиешлеген истә тоту зарур. Этник-мәдәни ихтыяҗлар, милли төбәк үзенчәлекләре программаның вариатив өлешендә чагыла. Әлегә Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан мәктәпкәчә белем бирү оешмалары өчен бердәм үрнәк белем бирү программасы расланмаган, рәсми реестрга кертелмәгән. Димәк, мәктәпкәчә белем бирү оешмалары, төп норматив документларны файдаланып, әлегә үз программаларын төзи һәм эш юнәлешләрен билгели ала.
Программа эчтәлеге балаларны шәхес буларак формалаштыруны, аларның төрле юнәлештәге эшчәнлектә кызыксынуларын һәм сәләтләрен үстерүне тәэмин итәргә тиеш. Шулардан чыгып ,без, ”Туган якны өйрәнәбез” милли-региональ тәрбия программасын төзедек. Вариатив өлештә куелган, балаларда милли үзаң тәрбияләү, халык педагогикасы нигезендә әдәби-әхлак нормалары тәрбияләү максаты н куйдык.
Безнең милли-региональ “Туган якны өйрәнәбез” тәрбия программасының **фәнни яңалыгы** түбәндәгечә: милли җанлы шәхес сыйфаты буларак үз милләтенә һәм башка милләт халкына булган карашларын формалаштыруны үз туган җирен хөрмәт итүче патриот, мәдәни белемле шәхес тәрбияләүдән башлау.
“Берәү башка телне өйрәнмәкче булса, иң
элек үз телеңнең грамматикасын яхшы
белсен”. ... дигән халкыбызның бөек шагыйре Г Тукай.Балаларны ана телендә яхшы итеп сөйләргә өйрәтү,тел системасының фонетик,лексик,грамматик төзелешен формалаштыру,бәйләнешле

сөйләм үстерү максатыннын, “Туган телдә сөйләшәбез” укыту методик комплектын кулланабыз.УМК балаларга телебезнең матурлыгын,байлыгын аңларга,үзләрендә күркәм сыйфатлар тәрбияләргә,туган җиребезгә,телебезгә мәхәббәт,әти-әниләргә,өлкәннәргә карата хөрмәт-итәгать тәрбияләргә,тыйнаклык,шәфкатьлелек кебек сыйфатлар булдырырга ярдәм итә.

Балаларыбызны милли җанлы итеп тәрбияләү туган телебез һәм әдәбиятыбызның чишмә башында торган бөек шәхесләребез турында мәгълүмат бирүдән башлана,шагыйрьләребез,язучылар әсәрләре белән таныштырудан башлана.Болар сойләм үстерү шөгыльләре вакытында,режим моментларында, “Туган телем-иркә гөлем”проекты кысаларында башкарылды.  Апрель ае – Тукай ае. Балалар белән бергәләп, сөекле шагыйребез хөрмәтенә махсус рәвештә шигырьләр ятладык, җырлар өйрәндек, балаларга зур шатлык китерде, ул аларның хәтерләренә тирән уелып калды. Татар халкының милли мәгариф системасы электән килгән “яхшы, мул тормышта яшәү өчен, кеше, иң беренче чиратта, белемле һәм тәрбияле булырга тиеш” дигән акыллы фикергә таянып эш итә. Бу фикер бөтен мәгърифәтчеләр өйрәтмәләренә барып тоташа, белем бирү белән тәрбия бирүне бәйләп алып бару принцибын алга чыгара. Күп милли мәдәниятле Россия шартларында башка милләтләр мирасы белән таныш булу зарур.Курше республикалар турында да мәгълүматлар туплап альбомнар ясадык,шөгыльләр вакытында ,режим моментларында да аларны еш кулланабыз. Без,Богады “Кояшкай балалар бакчасында мирас булып буыннан буынга күчеп килә торган байлыкка зур игътибар бирәбез. Йола, гореф-гадәт һәм бәйрәмнәребез безнең бик матур һәм истәлекле үтә.

Һәр милләтнең үзенә генә хас яшәү, көнкүреш итү, үз-үзен тоту кагыйдәләре формалаша. Татар халкында “Аулак өйләр”, “Кичке уеннар” аша аларның күбесе буыннан буынга тапшырылган, заман таләпләреннән чыгып камилләштерелгән. Вакыт узу белән, милли үзенчәлекләрнең кайберләре юкка чыга, яңалары барлыкка килә. Милли үзенчәлекләр – милли үзаңны формалаштыруга зур йогынты ясый торган әһәмиятле фактор.

Бәйрәмнәр, гореф-гадәтләрне яшь буыннарга  өйрәтүдә төп вазифаны гаилә башкара. Кош, оясында нәрсә күрсә, очканда шуны эшли, ди халык. Гаилә милли традицияләргә уңай караштa булса,

татар миллəтенең үзенчəлеклəрен исəпкə алып яшəсə,балалар дə шулай яшəргə күнегəлəр. Милли традициялəр белəн яшəү балага нинди исем кушудан башланып, аның туган телендə теле ачылуны, нинди уенчыклар белəн уйнавын, нинди киемгə күнегүен, йортта урнаштырылган тəртипне, нинди азыклар белəн туклануны, туганнар арасындагы мөнəсəбəтлəрне һəм башкаларны колачлый. Шуны исəпкə алып, бакчабызда “Заман гаиләсе”проекты кысаларында гаилə шэҗəрəлəре күргəзмəсе, “Заман гаилəсе” бəйгесе үткəрелде.

Халык бəйрəмнəре – шул халыкны миллəт итеп берлəштерə торган чараларның берсе. Һəр миллəтнең үзенə генə хас бəйрəмнəре була. Алар халыкның милли горурлык, милли хислəр культурасын тəрбиялəргə ярдəм итеп кенə калмыйлар, ə шул хислəрне кичергəн кешелəрдə рухи канəгатьлəнү дə тудыралар. Əгəр дə халык бəйрəмнəре югала, юкка чыга икəн, бу инде аның рухи байлыклары саега баруын чагылдыра. Халык бəйрəмнəре һəр кешенең йөрəк түрендə саклана, чөнки җыр, бию, яңа көйлəр башкару, очрашу – танышулар шушы көннəрдə була. Алар аны кайда гына булса да – үз авылына, төбəгенə тартып тора. Шуңа күрə без дə үзебезнең “Кояшкай “ балалар бакчасында əти-əнилəр белəн, əби-бабайлар катнашында милли бəйрəмнəр үткəрəбез: “Сабантуй”, “Нəүрүз”, “ Сөмбелə”, “Карга боткасы”.

Əнилəр милли ашларны хəзерлəү традициялəрен яшь буынга турыдан – туры тапшыру вазифасын башкарсалар, алар үз осталыкларын кызларына тапшырып кына калмыйча, бу эшчəнлекне бергəлəп тагын да камиллəштерсəлəр –халкының килəчəгедə дə матур булыр. “Ягез,эле əнилəр”уеннарын да милли рухта үткəрəбез.Оста əнилəр үз һөнəрлəрен кызларына бəйгелəрдə күрсəтəлəр.

Əти-əнилəр үрнəгендə һəм йогынтысында милли киемнəрнең кайберлəре əкренлəп кире тормышка кайтарыла башлады. Калфаклы, ак яулыклары кызлар, чигүле түбəтəйлəрне егетлəр бəйрəмнəрдə генə түгел, башка вакытларда да гадəти күренешкə əверелеп бара. Балаларыбызны “Татар егете,татар кызы”,“Бию мəйдан”,“Йолдызлык”,”Без бергə”(Театр мод) конкурсларына катнаштырып милли киемнəребезнең матур үрнəклəрен курсəттелəр. Əти-əнилəрнең милли традициялəребезне саклаудагы роле балаларны төрле эшчəнлектəн тыш чараларга тартуда да күренə. Алар үзлəренең балаларын, зур сабырлык белəн төрле

конкурсларга әзерлиләр. Милли юнәлештәге “Кулъяулыгым – бүләгем” конкурсында да матур чыгыш ясап,чигү сәнгатенең югарылыгын күрсәттеләр. “Милли бизәкләребез” проектын йомгаклап ата-аналар өчен мастер класс үткәрдек. Бу методик эшчәнлек нигезендә,беренчедән яңа технология-фасилитация алымын өйрәнү булса,икенчедән,милли бизәкләрне җайлы,уңайлы чаралар ярдәмендә төшерергә өйрәнүята.Әлеге чара ата-аналар белән аралашуда компетынтлылык,профессиональ осталык,милли бизәкләр өйрәнүне кызыклы итеп оештырырга мөмкинлек бирде.Тәрбиячеләребез “Милли курчаклар” конкурсында катнашып,башкорт,мордва, рус киемнәренең матур үрнәкләрен булдырдылар. “Туган –җирем Татарстан” информация почмагын бай,зәвыклы материаллар белән тулыландырдылар,милли лэпбуклар эшләделәр. Бу мисаллар барысы да әгәр теләк булса, күңел бирелсә, милли гореф-гадәтләребезне саклап кала алуыбызны күрсәтә.

Без үз эшебезне татар халык авыз иҗатына, милли горефгадәтләренә, уеннарына да зур игътибар итәбез, һәм шул юнәлештә эш алып барабыз. “Әкиятләр илендә уйный-уйный үсәбез” проектын башкарганда бик күп бишек җырлары, әкиятләр, табышмак –сынамышлар, мәкаль, әйтемнәр тупладык. Көн дәвамында, эшчәнлек барышында, саф һавада йөргәндә, уйнаганда татар халык авыз иҗатын киң кулланабыз.. Балаларда татар халык уеннарына да кызыксыну уятырга торышабыз. Безнең якларда яратып уйнала торган җырлы – сүзле уеннарда: “Чума үрдәк – чума каз”, “Миңлебай”, “Күрсәтәле үскәнем”, “Йөзек салыш”,“Кәрия – Зәкәрия”, “Без, без, без идек” теләп катнашабыз. Бу уеннар милли тәрбия чарасы. Халкыбыз гореф-гадәтләре, йолалары, тормыш-көнкүреше чагылыш тапкан уеннар балаларга үз көченә ышаныч, кумәклелек, ярдәмләшү кебек күркәм сыйфатларда тәрбияли. Балаларның рухи яктан бай, физик яктан сау- сәламәт булып үсүләрендә уеннарның әһәмияте бик зур.

Халкыбызның рухи байлыгын, тарихи-мәдәни мирасын түкми-чәчми яшь буынга җиткерү өчен, музейлардан башка күз алдына да китереп булмый. Татар халкының мәдәнияте белән даими таныштырып тору өчен безнең үзебезнең балалар бакчасында дә “Туган як” мини-музее бар.Музей кечкенә булса да эчтәлеге бай. Туган авылыбыз тарихын чагылдырган экспанатлар җитәрлек.Тәрбиячеләр белән берлектә түбәндәге альбомнарны

ясадык: “Богады авылы: халкының үткәне һәм хәзерге тормышы”, “Авылыбызның күренекле кешеләре”, “Ачык сандык”, “Авылым һөнәрчеләре”.Кечкенәләр төркеме балалары белән  музейдагы җиһазлар, аларның исемнәре,  белән таныштырсак, ә зурлар төркемендә аларның тарихи эзлеклеген күрсәтергә тырышабыз.Баларга туган як музеена карата горурлык хисе тәрбияләүне куйган максатларыбызга ирешергә тырышабыз. Соңыннан музейда күргән-белгәннәре турында әңгәмә корабыз. Мәктәп бинасында урнашкан “Туган як”музеенда да,Актаныш районы “Туган як” музеена да балалар белән экскурсиягә барабыз, күргәзмәләр белән танышабыз. Милли тәрбия – ул, әлбәттә, иң элек туган яктан башлана. Үзенең газиз нигезе турында сөйләшүне һәркем ярата. Шуңа күрә без дә әти-әниләрне туган якка багышланган бәйрәм чараларына чакырдык, бергәләп балаларга туган җир кадере хакында сөйләдек.Авылыбыз зур,5 авылны(Иске Богады, Яңа Богады,Солтангол, Яңа Җияш,Югары Богады)берләштерә.Истәлекле,тарихи матур урыннар, челтерәп аккан чишмәләр күп, шуларның берсе “Пар чишмә”. Ул чишмә матур,ләкин һәрвакыт тәрбия сорый. Без Чишмә урамы ата-аналары берләшеп чистарту өмәләре ясыйбыз, “Карга боткасы”, “Кече сабантуй”, “Яңа елны каршылау” бәйрәмнәрен шушы чишмәнең самавыр борынынннан агып чыгып, кешеләрнең тәннәренә сихәтлек бирә сулары янында үткәрергә яратабыз.

Без – бала күңеле белән эш итүче тәрбиячеләр бу мәсьәләгә аеруча игътибар күрсәтергә тиешле. Чөнки нәкъ менә сабый чакта, дөньяга караш формалашканда баланың кальбенә үз милләтенә, диненә, гореф-гадәтләргә мәхәббәт орлыклары чәчеп калдыру кирәк.

Кыскасы, милләтебез тарихы һәм мәдәнияты - балалар өчен бик кызыклы өлкә. Кызыксынулары көчле булганга, өйрәтү, аңлату да җиңелгә килә. Шул рәвешле безгә, әлеге кызыксынудан файдаланып, сабыйларда милли узаң, горурлык тәрбияләү мөмкинлеге бирелә. Ә аннан дөрес файдалана белү безнең иҗтиһатыбыз дәрәҗәсен күтәрә.

Шулай итеп, бала үзен шәхес итеп тойсын өчен, аңарда милли үзаң формалашу зарур.  Шунлыктан балаларны бакчада тәрбияләүдә туган якны, туган телебезне ,халкыбызның гореф-гадәтләрен, бәйрәмнәрен өйрәнү һәм аларны куллану мөһим чараларның берсе булып тора.Без мәктәпкәчә белем бирү хәзмәткәрләре ата-аналар

белән берлектә кешелекле,милли аңлы шәхес,сәламәт рухлы патриот тәрбияли алсак,милли тәрбиянең роле шунда күренәчәк.

_